ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«22» сентябрь 2020ел № 97-р

Әгерҗе муниципаль районы җыелма командасының чаңгы ярышларында катнашуы турында

ТАССР мәгарифенең 100 еллыгына багышланган узышчы чаңгычылар арасында җәйге чемпионат һәм Татарстан Республикасы беренчелеге турында 2020 елда Татарстан Республикасы спорт министрының беренче урынбасары һәм Татарстан Республикасы Чаңгы узышлары һәм биатлон федерациясе президенты тарафыннан расланган Нигезләмәне үтәү максатында:

1. Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга:
- 2020 елның 22 сентябреннән 24 сентябренә кадәр Зәй шәһәрендә узачак чаңгы ярышлары буенча Әгерҗе муниципаль районы җыелма командасында катнашучылар составы (1 нче кушымта);
- 2020 елның 22 сентябреннән 24 сентябренә кадәр Зәй шәһәрендә узачак чаңгы ярышлары буенча Әгерҗе муниципаль районы җыелма командасы өчен чыгымнарның сметасы (2 нче кушымта).

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм бүлегенә 2020 елның 22 сентябреннән 24 сентябренә кадәр Зәй шәһәрендә узачак чаңгы ярышлары буенча Әгерҗе муниципаль районы җыелма командасы катнашуын оештырырга.

2020 елның 22 сентябреннән 24 сентябренә кадәр Зәй шәһәрендә узачак чаңгы ярышлары буенча җыелма команда җитәкчесе итеп Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Спорт мәктәбе” муниципаль бюджет учреждениесе тренеры Яркеев Евгений Владимировичны билгеләргә.

2. 2020 елның 22 сентябреннән 24 сентябренә кадәр Зәй шәһәрендә узачак чаңгы ярышларында җыелма командан катнашуын тәэмин итү максатларында транспорт чарасы - Лада Грант автомобиле (теркәү билгесе А344КР 116RUS, хокук иясе - Яркеев Евгений Владимирович) бирүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И. И. Шәмсетдинов**